**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 октябрь № 811

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында» 2012 ел, 25 май, 422 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында» 2012 ел, 25 май, 422 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 308 нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

әлеге карар белән расланган «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына конкурсның гала-концертын үткәргән вакытта гражданнар иминлеген һәм хокук тәртибен саклауны тәэмин итүдә булышлык күрсәтергә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\811.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 25 май, 422 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының 2015
ел, 29 октябрь, 811 нче карары
редакциясендә)

**«Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында
нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы.

2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – татар халык җырларын һәм татар композиторлары әсәрләрен пропагандалау, яшьләрне милли мәдәни байлыклар белән таныштыру, сәләтле яшь башкаручыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, аларның иҗади потенциалын үстерү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

татар халык һәм профессиональ музыкасын тарату һәм пропагандалау, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында;

татар халык җырларын һәм татар композиторлары әсәрләрен иң яхшы башкаручы яшьләрне ачыклау;

яшьләрнең иҗади сәләтләрен тормышка ашыруда булышлык күрсәтү.

3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга татар музыкаль әсәрләрен башкаручы 15 яшьтән 35 яшькә кадәрге башкаручылар,  вокаль һәм инструменталь ансамбльләр (алга таба – катнашучылар) кертелә.

Вокаль һәм инструменталь ансамбльләрнең яшь буенча төркеме коллективта катнашучыларның уртача яше буенча билгеләнә.

3.2. Конкурста катнашучыларның юлда йөрүенә, яшәвенә һәм туклануына җибәрүче як исәбеннән түләнә.

## 4. Оештыру комитеты

4.1. Конкурсны оештыру, үткәрү һәм йомгаклар ясау өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән республика оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) төзелә.

4.2. Оештыру комитеты вазыйфалары:

конкурс этапларын эшләү;

конкурсның башкарма продюсерын билгеләү;

жюри составын, аның эш тәртибен төзү һәм раслау;

конкурсның һәр этабында номинацияләр буенча катнашучылар һәм җиңүчеләр исемлеген төзү;

конкурсны оештыруны әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итү.

4.3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе буенча гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыру өчен Оештыру комитеты, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән килештереп, үзе составыннан башкарма продюссер билгели.

4.4. Конкурсның башкарма продюссеры вазыйфалары:

конкурсны үткәрү барышында оештыру, технологик һәм иҗади контрольне тәэмин итү;

сайлап алу турларын үткәрү һәм сайлап алу турларын әзерләү өчен мәйданчыклар билгеләү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары), Россия Федерациясе субъектлары белән багланышларны оештыру;

конкурска заявкаларны анализлау һәм гомумиләштерү;

конкурс документациясен алып бару;

жюри һәм Оештыру комитеты эшен тәэмин итү;

Оештыру комитетына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына һәм массакүләм мәгълүмат чараларына конкурсны үткәрү барышы турында оператив мәгълүмат бирү.

## 5. Конкурсның жюрилары

5.1. Конкурсның жюрилары (алга таба – жюрилар) составында рәисе, рәис урынбасары һәм жюри әгъзалары булган җиде кешедән торган мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге белгечләр, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан оеша.

5.2. Жюри әгъзалары составын һәм аларның эш тәртибен, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән килештереп, Оештыру комитеты раслый.

5.3. Жюри утырышы, анда жюри әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашкан шартларда тулы хокуклы санала.

## 6. Конкурсның номинацияләре

6.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Социаль вокал» (ир-ат һәм хатын-кыз тавышы):

15 яшьтән 20 яшькәчә яшь категориясе арасында: ике беренче премия, ике икенче премия, ике өченче премия;

21 яшьтән 35 яшькәчә яшь категориясе арасында: ике беренче премия, ике икенче премия, ике өченче премия;

Россия Федерациясе төбәкләре һәм якын һәм ерак чит илләр вәкилләре арасында: ике беренче премия, ике икенче премия, ике өченче премия;

«Инструменталь башкару»: бер беренче премия, бер икенче премия, бер өченче премия;

«Вокаль һәм инструменталь ансамбльләр»: бер беренче премия, бер икенче премия, бер өченче премия;

«Академик вокал»: бер беренче премия, бер икенче премия, бер өченче премия.

Оештыру комитеты карары белән татар музыка культурасының танылган эшлеклеләренә багышланган истәлекле һәм юбилей даталар нигезендә конкурсның өстәмә ике номинациясе раслана.

6.2. Конкурс йомгаклары буенча тамашачылар мәхәббәте призы һәм Гран-при бирелә.

6.3. Һәр номинация буенча акчалата бүләкләрнең зурлыгы конкурсны үткәрүгә бүлеп бирелә торган финанслар күләмнәренә бәйле һәм ел саен Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана.

## 7. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

7.1. Конкурс елга бер тапкыр үткәрелә.

7.2. Конкурста катнашучылар һәр этапта татар телендә бер татар халык җырын һәм әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә татар композиторларының тәкъдим ителгән исемлеге нигезендә татар композиторы әсәрен (җырын) башкара.

7.3. Конкурста катнашу өчен кандидатлар түбәндәге документларны тапшыралар:

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсында катнашуга анкета-заявканы;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча, электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында аудио- һәм видеоматериаллар теркәп (бер әсәрнең яңгыраш вакыты – иң күбе 5 минут), конкурсның беренче этабында катнашу өчен «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсында чыгыш ясау программасын.

Анкетага түбәндәге документлар теркәлә:

шәхси счетның банк реквизитлары;

паспорт күчермәсе (1, 2, 5 битләр);

салым түләүченең тәңгәлләштерү санын (ИНН) бирү турында таныклык күчермәсе;

дәүләт пенсия иминияте иминиятләве таныклыгы күчермәсе.

Вокаль һәм инструменталь ансамбльләр коллективларның җитәкчеләре документлары күчермәләрен тапшыра.

Конкурста катнашу өчен заявкалар катнашучы документлары белән агымдагы елның 1 ноябренә кадәр Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы адресы буенча («Татар моңы» конкурсының башкарма продюсерына» тамгасы белән) яки e-mail: tm@tatar.ru. адресы буенча электрон почтага җибәрелә.

7.4. Конкурсны үткәрү графигын һәм вакытларын Оештыру комитеты раслый һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыра.

7.5. Конкурс өч этапта үткәрелә:

беренче этап сайлап алу туры була һәм агымдагы елның 1 ноябренә кадәр турыдан-туры һәм читтән торып катнашу формаларында уза. Турыдан-туры катнашу формасы Татарстан Республикасы муниципаль районнарына, Россия Федерациясе субъектларына (шәһәр округларына) карарга чыгулар барышында конкурсантларны сайлап алуны күздә тота. Читтән торып катнашу формасы әлеге Нигезләмәнең 7.3 пункты нигезендә аудио- һәм видеоматериаллар һәм документлар тапшыруны күздә тота.

Беренче этап җиңүчеләре ачык тавыш бирүдә булган жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән билгеләнә.

Беренче этап җиңүчеләре исемлеге агымдагы елның 5 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла. Беренче этап җиңүчеләре конкурсның икенче этабында катнашалар.

Икенче этап агымдагы елда конкурсның беренче этабы тәмамланганнан соң 10 календарь көн узгач үткәрелә. Икенче этап җиңүчеләре ачык тавыш бирүдә булган жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән билгеләнә. Икенче этап турыдан-туры телевизион эфирда трансляцияләнә. Икенче этап җиңүчеләре конкурсның өченче этабында катнашу өчен уза.

Өченче этап агымдагы елда конкурсның икенче этабы тәмамланганнан соң биш көн эчендә телевизион форматта туры эфирда үткәрелә. Катнашучылар берәр әсәр башкара.

Өченче этап җиңүчеләре ачык тавыш бирүдә булган жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән билгеләнә.

Баллар суммасы буенча жюри әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында расланган критерийләр буенча һәр номинациядә катнашучылар рейтингын булдыра.

Баллар тигез булган очракта рәислек итүче (жюри рәисе яки аның урынбасары) тавышы хәлиткеч була.

Өченче этап йомгаклары буенча һәр номинациядә рейтингта беренче өч позицияне алган катнашучылар конкурс җиңүчеләре дип танылалар.

Өченче этапта тамашачыларның интерактив турыдан-туры сайлау юлы белән туры эфирда чыгыш ясау йомгаклары буенча иң күп җыелган тавышлар нигезендә тамашачылар мәхәббәте бүләге җиңүчесе билгеләнә.

## 8. Конкурста сайлап алу критерийлары

8.1. Конкурсның һәр этабында жюри өчен сайлап алу буенча төп критерийлар түбәндәгеләр:

катнашучыларның башкару осталыгы (техника, хискә бирелү, артистизм) (0-10 балл);

чыгышны бизәү (костюм, реквизит, яктылык җиһазларыннан файдалану, музыка белән тәэмин итү) (0-10 балл);

сәхнә культурасы.

## 9. Конкурска йомгаклар ясау һәм бүләкләү

9.1. Номинацияләр буенча жюринең йомгаклау карары булган жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән раслана.

9.2. Гран-при бирү турында яисә бүләкне бөтенләй бирмәү турында карар жюри әгъзалары һәм Оештыру комитеты тарафыннан коллегиаль кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

9.3. Катнашучыларның чыгышлары теге яки бу номинациядә конкурс таләпләренә һәм конкурсның сайлап алуы критерийләренә туры килмәгән очракта жюри үзендә урыннар бирмәү хокукын калдыра.

9.4. Жюри һәм Оештыру комитеты беркетмәләре нигезендә агымдагы елның 30 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының конкурс җиңүчеләре турында боерыгы чыгарыла.

9.5. Конкурс җиңүчеләре исемлеге боерык чыккан вакыттан соң өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

9.6. Оештыру комитеты конкурс җиңүчеләрен бүләкләү өчен гала-концерт оештыра, аларга дипломнар һәм акчалата бүләкләр тапшырыла.

9.7. Гала-концертны үткәрү урыны һәм вакыты турында мәгълүмат агымдагы елның 30 ноябреннән соңга калмыйча Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында һәм бүтән массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

«Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Әсәрләре башкару өчен тәкъдим ителгән татар композиторлары
ИСЕМЛЕГЕ

Абдуллин Рәшид Фәрукъ улы,
Әхиярова Резеда Зәки кызы,
Әхмәтов Фасыйл Әхмәт улы,
Байтирәк Илһам Илгиз улы,
Гатауллин Риф Хаббул улы,
Дәүләтшин Илфат Мәҗит улы,
Енекиев Ренат Әхмәт улы,
Җиһанов Нәҗип Гаяз улы,
Закиров Илгиз Тимершәех улы,
Имашев Мәсгуть Габдрахман улы,
Кәлимуллин Рәшид Фәһим улы,
Ключарев Александр Сергеевич,
Мәҗитов Илгиз Габидулла улы,
Мәҗитов Шакир Хафиз улы,
Макаров Марс Андреевич,
Мортазин Фирзәр Солтан улы,
Мозафаров Мансур Әхмәт улы,
Садыйкова Сара Гариф кызы,
Сәйдәшев Салих Җамалетдин улы,
Тимербулатов Шамил Харис улы,
Усманов Оскар Вадим улы,
Хәбибуллин Заһит Вәли улы,
Хәйретдинов Зөфәр Гыйлметдин улы,
Хисамов Ифрат Нигъмәт улы,
Шәрифуллин Шамил Камил улы,
Яруллин Мирсәет Заһидулла улы,
Яхин Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы.

___

«Татар моңы» халыкара
телевизион яшь
башкаручылар конкурсын
әзерләү һәм үткәрү турында
нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

«Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар
конкурсында катнашуга
АНКЕТА-ЗАЯВКА

Башкаручы:
Ф.И.Ат.ис./ансамбль
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
Туу көне һәм урыны:
_______________________________________________________________________
Яшәү урыны (адресы һәм телефоны): _____________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
Паспорт мәгълүматлары:
__________________________________________________ ИНН:
___________________________________________
Пенсия иминиятләве таныклы: __________________________________________
Белеме (уку йорты исеме, тәмамлау елы) : ________________________________
_______________________________________________________________________
Эш/уку урыны:
_______________________________________________________________________
Башка фестиваль, конкурсларда катнашу хакында белешмәләр: ________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
Җитәкче турында мәгълүмат:
Ф.И.Ат.ис. _____________________________________________________________
Туу көне һәм урыны: _____________________________________________________
Белеме (уку йорты исеме, тәмамлау елы): __________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
Өй адресы, индекс:
_____________________________________________________________________
Телефон, e-mail:__________________________________________________

Кем исеменә чакыру җибәрелә (Җитәкче Ф.И.Ат.ис., адрес, телефон, факс):
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

Аккомпаниаторга ихтыяҗ:  баян, фортепиано *(кирәклесенең астына сызарга)*
«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июнендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә минем персональ мәгълүматларымны файдалануга каршы килмим*

Тутыру датасы: __________________________
Шәхси имза:  _____________ / _______________________/

Җибәргән оешма җитәкчесе
имзасы һәм мөһере:      ______________ / ____________________________

--------------------------------
<*>  Анкетага түбәндәге документлар күчермәләрен теркәргә: паспорт, ИНН, пенсия иминиятләве таныклыгы, диплом.

«Татар моңы» халыкара
телевизион яшь
башкаручылар конкурсын
әзерләү һәм үткәрү турында
нигезләмәгә 3 нче кушымта

Форма

«Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсында
чыгыш ясау программасы
(I, II, III этаплар)

Башкаручы ______________________________
Номинация _______________________________

| Т/с | Әсәр исеме | Композитор | Сүзләр авторы | Озынлыгы | Музыкаль озатып бару төрен (фонограмма (-) аккомпанемент) күрсәтергә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |
| 4. | | | | | |
| 5. | | | | | |
| 6. | | | | | |

__________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 25 май, 422 нче карары
белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 29 октябрь, 811 нче
карары редакциясендә)

«Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, оештыру комитеты рәисе |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционарлык җәмгыяте генераль директоры, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Вафин Адел Юныс улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Закиров Ринат Зиннур улы | Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры |
| Мөхәмәтҗанов Фәргать Усман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының иҗтимагый тәртипне саклау полиция башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Фәттәхов Энгель Нәвәп улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Фәтхетдинов Салават Зәки улы | «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирүче мәгариф учреждениесенең татар эстрадасы кафедрасы мөдире, «Салават» эстрада театры» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры (килешү буенча) |
| Хәбибуллин Сәгыйт Мулланур улы | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе (академиясе)» федераль дәүләт бюджет югары һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениесенең татар музыкасы факультеты деканы (килешү буенча) |
| Хәшимова Нурия Миңнәхмәт кызы | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм күрсәтү фонды башкарма директоры (килешү буенча) |
| Шиһапова Илсөяр Илдүс кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирүче мәгариф учреждениесенең телевидение кафедрасы доценты (килешү буенча). |

_______________________________